Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Югары Дәүләзәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2 ноябрь, 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең Югары Дәүләзәр торак пунктында 2025 елның 2 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 11 (унбер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 10 (ун).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 10 (ун).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Сез 2026 елда Югары Дәүләзәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нагорный ур.)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Екатериновка авыл җирлеге башлыгы П.И. Егоров